**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2019 Казан ш. № 82

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законының 17 маддәсе 1 өлешенең 3 пункты буенча

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирүнең теркәлә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
_19.03.2019_______ дан
__82_____ номерлы
боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан
рөхсәт бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе 2004 елның 27 июленнән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» федераль законының 17 маддәсе 1 өлешенең 3 пункты буенча эшләнгән.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешмалар) белән идарә итүдә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү процедурасын җайга сала. Әлеге Тәртип эш бирүче вәкиле булып Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә тарала.

2. Түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның

коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт турында гариза (алга таба – гариза) дәүләти гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма формада әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы буенча төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре гаризасын коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка бирә (алга таба – җаваплы зат).

4. Җаваплы зат гариза кергән көнне аны әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча журналда терки.

5. Җаваплы зат гаризаны алдан карауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында җаваплы зат гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән язмача аңлатмалар һәм коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырыла торган функцияләрне билгели торган документларны соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат гаризаны, бәяләмә һәм башка материалларны теркәп, карау өчен коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки идарә итүнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен (булганда) министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) гаризаны алган көннән соң ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат министр (зат, аның вазыйфаларын башкаручы) карар кабул иткән көннән алып ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа, имза куйдырып, кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторның мөһере белән расланган министрның резолюциясе

белән гариза күчермәсен тапшыра. Министр резолюциясе белән гаризаның оригиналы гражданлык хезмәткәренең Шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керер өчен эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы спорт министры

В.А.Леоновка

____________________________________

____________________________________

(Ф.И.Аи., били торган вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе,

____________________________________

яшәү урыны адресы,

____________________________________

телефон номеры)

## Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү турында гариза

Миңа түләүсез нигездә ________________________________________________.
башкарма комитетның яки коллегиальидарә органының атамасы
сыйфатында идарә итүдә катнашырга, коллегиаль идарә органы (кирәклесенең астына сызарга) ________________________________________________
(җәмәгать оешмасының, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының,
____________________________________________________________,
бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәтенең атамасы)
____________________________________________________________

____________________________________________________________

составына керергә рөхсәт итүегезне сорыйм.

______________ ________________ ____________________________
(дата) (имзлар) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керер өчен эш бирүченең вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүченең вәкиле тарафыннан
рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Дата | Үтенечнәмә биргән кешенең Ф.И.Аи., вазыйфасы | Үтенечнәмә бирүченең имзасы | Ф.И.Аи. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |